ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26. 03. 2026 Олы Кайбыч ав. № 172

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә башкарма документация формалаштыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарма документация составын һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 маендагы 344/пр номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә башкарма документация формалаштыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында» 2023 елның 29 декабрендәге 1751 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 1.5 өлешендә каралган башкарма документларны булдыру һәм алып бару капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү эшләрен башкаруны, башкарма документацияне электрон рәвештә булдыру һәм алып бару буенча подрядчы (башкаручы) йөкләмәләрен күздә тоткан муниципаль контрактка (контрактка, килешүгә) кертеп, кәгазьдә кабатламыйча, электрон документлар рәвешендә (алга таба - башкарма документация электрон рәвештә) тәэмин ителә дип билгеләргә.

2. Капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүләр кысаларында финансланучы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетына капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә муниципаль контрактларга башкарма документацияне электрон рәвештә булдыру һәм алып бару буенча подрядчы (башкаручының) йөкләмәләрен кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Е.Г.Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров